Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 июль 2022 ел № 153

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 113 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарга 1 нче кушымтаның 4 бүлеге 4.1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.3. Контроль чаралар контрольдә тотыла торган зат белән хезмәттәшлек иткәндә гамәлгә ашырыла, түбәндәге нигезләрдә тикшереп тору органы тарафыннан үткәрелә:

1) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуын ачыклау;

2) контроль чаралар уздыру планына кертелгән контроль чараларны уздыру срокларын билгеләү;

3) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдә тотыла торган затларга карата контроль чаралар уздыру турындагы йөкләмәсе;

4) законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча үтәү кысаларында контроль чара уздыру турында прокурор таләбе;

5) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында контроль орган карарын үтәү срогы тәмамлану.

Контроль чаралар, контроль орган эше планнарындагы, шул исәптән Федераль законда билгеләнгән очракларда да, биремнәрне дә кертеп, контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары заданиеләре нигезендә инспекторлар тарафыннан башкарыла.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов